КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 2 август г.Казань № 613

«Мин күк йөзен сайлыйм!» авиация бәйрәмен үткәргәндә су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6, 25 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренең 1.3 пункты нигезендә, «Мин күк йөзен сайлыйм!» авиация бәйрәмен үткәргәндә кешеләр тормышы иминлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

2024 елның 3 августында 16 сәгать 00 минуттан 21 сәгать 00 минутка кадәр Казансу елгасында Кремль дамбасыннан Миллениум күперенә кадәр азсыешлы, ял итү, җилкәнле спорт судноларын файдалануны тыярга;

әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән судноларны файдалануны тыю «Мин күк йөзен сайлыйм!» авиация бәйрәмен әзерләүгә һәм үткәрүгә җәлеп ителгән судноларга кагылмый.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

әлеге карарда билгеләнгән тыюны үтәү максатларында Казансу елгасы акваториясенең әлеге участогында көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итәргә;

халыкка кертелә торган тыю турында, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

3. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә әлеге карарда билгеләнгән тыюны үтәү максатларында көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин